

Һәр челтәр, һәр ярдәм - Жинvгә таба тагын бер адым ул. Үзебезнекеләрне ташламыйбыз, ярдәм кулы сузабыз.
Илебез очен катлаулы чорда, Ватаннын ин яхшы уллары янадан vз Ватаннары чикләрен якларга мәжбvр булганда, СВО катнашучыларына момкин кадәр ярдәм итvчеләр аз тvгел. Һәркем уртак эшкә vз олешен кертергә тырыша: кемдер СВО зонасына vз транспортын жибәрә, икенчеләре андагы якташлары очен посылкалар жыя.
Мордовия халкы да СВО катнашучыларына ярдәм кvрсәтvен дәвам итә. Битараф булмаган кешеләр Ватанны саклаучыларга кирәк булган ботен нәрсәне китерә алсын очен, гуманитар ярдәм кабул итv нокталары һәр районда эшли. Маскировка челтәрләрен vрvнен Ботенроссия хәрәкәтенә ботен Мордовия кушылды, хәтта мәктәп укучылары да ятьмә vрә. Мәсәлән, Ромоданово районы Белозерье мәктәп директоры вазыйфаларын башкаручы Айса Раис улы Ахмяров житәкчелегендә, даими нигездә, педагоглары һәм укучылары СВОда катнашучылар очен маскировка челтәрләре vрәләр. Шулай, 25 ноябрь конне Белозерье урта мәктәбенә махсус хәрби операция ветераны Миразым Сяяф улы Исмаилов килгән. Алтынчы «б» сыйныф укучылары «Сыйныф очрашулары» проектында катнаштылар, анын кысаларында Миразым Сяяф улы СВОда хезмәт итvләре турында сойләде һәм бу конне маскировка челтәрен бергәләп vрделәр.



Дубенка районы Ломаты авылында гомер итvче Мәзидә Якуп кызы Муракаева, Тәнзилә Айса кызы Пикеева, Сафия Хәмзә кызы Филлипова, Тәкия Габделхак кызы Мусина, Фәvзия Бари кызы Мусина, Сафия Али кызы Сайфетдинова, Газимә Фәрит кызы Фәхретдинова, Фаилә Исмәгыйль кызы Абдюшева, Альфинур Исмаил кызы Алеева, Маидә Закарья кызы Хусаинова, Рәзимә Таиб кызы Рахметуллова, Альмира Бари кызы Раимова, Нажия Идрис кызы Рахметуллова, Альфия Няим кызы Үзбякова, Альфия Фатих кызы Жалилова, Факия Фәрит кызы Манерова, Рамия Таһир кызы Муракаева, Рафик Ахать улы Муракаев СВО зонасында булган Россия солдатлары очен маскировка челтәрләре vрәләр. Ә Зегря Ряхимьян кызы Манакова ойдә челтәр очен тасмалар (заготовка) ясап бирә.
Туган якны ойрәнv мvзееннн оештыручы һәм шул ук вакытта житәкчесе булган Мәзидә Якуп кызы Муракаева Ломат авылы сайтында болай язган: “...Бvген, 13 ноябрь конне туган якны ойрәнv музеенда маскировка челтәре vрv эше дәвам итә. Авылдашлар чаранын моһимлеген анлыйлар һәм бу чарада бик теләп катнашалар.

